# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О развитии креативных (творческих) индустрий в Республике Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
18 апреля 2025 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 8 августа 2024 года № 330-ФЗ «О развитии креативных (творческих) индустрий в Российской Федерации» (далее – Федеральный закон) регулирует отдельные вопросы в сфере креативных (творческих) индустрий (далее – креативная индустрия) в Республике Татарстан, а также определяет полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в сфере креативных индустрий.

Статья 2. **Правовое регулирование в сфере креативных индустрий**

Правовое регулирование в сфере креативных индустрий основывается на Конституции Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан и осуществляется в соответствии с Федеральным законом, другими федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, настоящим Законом, другими законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

Статья 3. **Основные понятия, используемые в настоящем Законе**

Основные понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в том же значении, что и в Федеральном законе.

Статья 4. **Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в сфере креативных индустрий**

1. К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан в сфере креативных индустрий относятся:

1) законодательное регулирование отношений в сфере креативных индустрий;

2) осуществление контроля за исполнением законов Республики Татарстан в сфере креативных индустрий;

3) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

2. К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в сфере креативных индустрий относятся:

1) определение органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного в сфере креативных индустрий (далее – уполномоченный орган);

2) установление порядка формирования и ведения реестра субъектов креативных индустрий, осуществляющих деятельность в Республике Татарстан, в том числе порядка включения в указанный реестр и исключения из него сведений о субъектах креативных индустрий;

3) установление критериев отнесения физических лиц, юридических лиц и индивидуальных предпринимателей к субъектам креативных индустрий;

4) установление порядка подтверждения соответствия физических лиц, юридических лиц и индивидуальных предпринимателей критериям отнесения к субъектам креативных индустрий, установленным в соответствии с пунктом 3 настоящей части;

5) установление критериев определения приоритетных креативных индустрий в Республике Татарстан;

6) установление порядка размещения на официальном сайте Кабинета Министров Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» сведений об инфраструктуре поддержки креативных индустрий в Республике Татарстан, в том числе утверждение состава таких сведений, с учетом типового состава сведений об инфраструктуре поддержки креативных индустрий в субъектах Российской Федерации, утвержденного в соответствии с пунктом 4 части 2 статьи 4 Федерального закона, и размещение таких сведений, а также порядка размещения на указанном сайте информации, предусмотренной частью 2 статьи 14 Федерального закона;

7) определение имущества Республики Татарстан, относящегося к инфраструктуре поддержки креативных индустрий в Республике Татарстан;

8) определение имущества Республики Татарстан, используемого при формировании креативного кластера в Республике Татарстан;

9) создание организаций для реализации полномочий в сфере креативных индустрий;

10) осуществление иных полномочий в сфере креативных индустрий в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

3. К полномочиям уполномоченного органа в сфере креативных индустрий относятся:

1) осуществление подтверждения соответствия физических лиц, юридических лиц и индивидуальных предпринимателей критериям отнесения к субъектам креативных индустрий, установленным Кабинетом Министров Республики Татарстан;

2) формирование и ведение реестра субъектов креативных индустрий, осуществляющих деятельность в Республике Татарстан;

3) осуществление подтверждения соответствия территории критериям признания территории креативным кластером в порядке, установленном в соответствии с пунктом 3 части 1 статьи 4 Федерального закона;

4) формирование перечня приоритетных креативных индустрий в Республике Татарстан на основании критериев определения приоритетных креативных индустрий в Республике Татарстан, установленных Кабинетом Министров Республики Татарстан;

5) осуществление иных полномочий в сфере креативных индустрий в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

4. Кабинетом Министров Республики Татарстан или уполномоченным органом для реализации полномочий в сфере креативных индустрий могут формироваться консультационные и (или) экспертные органы.

Статья 5. **Реестр субъектов креативных индустрий, осуществляющих деятельность в Республике Татарстан**

1. Сведения о субъекте креативной индустрии включаются в реестр субъектов креативных индустрий, осуществляющих деятельность в Республике Татарстан, в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан.

2. Состав сведений о субъектах креативных индустрий, включаемых в реестр субъектов креативных индустрий, осуществляющих деятельность в Республике Татарстан, определяется в соответствии с Федеральным законом.

3. Сведения, содержащиеся в реестре субъектов креативных индустрий, осуществляющих деятельность в Республике Татарстан, включаются в единый реестр субъектов креативных индустрий в порядке, установленном в соответствии с пунктом 2 части 1 статьи 4 Федерального закона.

Статья 6. **Инфраструктура поддержки креативных индустрий**

1. Инфраструктура поддержки креативных индустрий определяется в соответствии с Федеральным законом.

2. Сведения об инфраструктуре поддержки креативных индустрий в Республике Татарстан размещаются на официальном сайте Кабинета Министров Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» в порядке, установленном в соответствии с пунктом 6 части 2 статьи 4 настоящего Закона.

3. Сведения об инфраструктуре поддержки креативных индустрий в Республике Татарстан представляются в федеральный орган исполнительной власти, уполномоченный на осуществление функций по выработке государственной политики и нормативно-правовому регулированию в сфере креативной экономики, в порядке, установленном указанным органом.

### Статья 7. **Меры государственной поддержки в сфере креативных индустрий**

1. В целях создания благоприятных условий для развития креативных индустрий субъектам креативных индустрий, которые включены в реестр субъектов креативных индустрий, осуществляющих деятельность в Республике Татарстан, и соответствуют условиям, установленным статьей 10 Федерального закона, могут предоставляться меры государственной поддержки в соответствии с законами и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

2. Государственная поддержка в сфере креативных индустрий может предоставляться путем оказания финансовой, имущественной, образовательной, консультационной, информационной и иной поддержки субъектам креативных индустрий.

3. Сведения об объеме затрат на создание, продвижение на внутреннем и внешнем рынках, распространение и (или) реализацию креативного продукта и объеме затрат на создание результатов интеллектуальной деятельности, а также сведения об объеме выручки от распространения и (или) реализации креативного продукта и объеме выручки от распоряжения правами на результаты интеллектуальной деятельности и средства индивидуализации, в том числе выручки от реализации материальных носителей, в которых выражены такие результаты и средства, предоставляемые субъектами креативных индустрий, получившими финансовую и (или) имущественную поддержку в сфере креативных индустрий, в соответствии со статьей 15 Федерального закона, включаются в реестр субъектов креативных индустрий, осуществляющих деятельность в Республике Татарстан.

### Статья 8. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
26 апреля 2025 года
№ 32-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 18 апрелендә
кабул ителде

## 1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» 2024 елның 8 августындагы 330-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләр (алга таба – креатив индустрия) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала, шулай ук креатив индустрияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен билгели.

## 2 статья. **Креатив индустрияләр өлкәсендә хокукый җайга салу**

Креатив индустрияләр өлкәсендә хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнә һәм Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

## 3 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

## 4 статья. **Креатив индустрияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Креатив индустрияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) креатив индустрияләр өлкәсендә мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) креатив индустрияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары үтәлешен тикшереп тору;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Креатив индустрияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) креатив индустрияләр өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын билгеләү (алга таба – вәкаләтле орган);

2) Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен, шул исәптән күрсәтелгән реестрга креатив индустрияләр субъектлары турында белешмәләрне кертү һәм аннан төшереп калдыру тәртибен, билгеләү;

3) физик затларны, юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны креатив индустрияләр субъектларына кертү критерийларын билгеләү;

4) физик затларның, юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның әлеге өлешнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән креатив индустрияләр субъектларына кертү критерийларына туры килүен раслау тәртибен билгеләү;

5) Татарстан Республикасында өстенлекле креатив индустрияләрне ачыклау критерийларын билгеләү;

6) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Татарстан Республикасында креатив индустрияләргә ярдәм инфраструктурасы турында белешмәләрне, Россия Федерациясе субъектларында креатив индустрияләргә ярдәм инфраструктурасы турында белешмәләрнең Федераль законның 4 статьясындагы 2 өлешенең 4 пункты нигезендә расланган үрнәк составын исәпкә алып, урнаштыру тәртибен билгеләү, шул исәптән мондый белешмәләрнең составын раслау, һәм мондый белешмәләрне урнаштыру, шулай ук күрсәтелгән сайтта Федераль законның 14 статьясындагы 2 өлешендә каралган мәгълүматны урнаштыру тәртибен билгеләү;

7) Татарстан Республикасында креатив индустрияләргә ярдәм инфраструктурасына керә торган Татарстан Республикасы мөлкәтен билгеләү;

8) Татарстан Республикасында креатив кластер төзегәндә файдаланыла торган Татарстан Республикасы мөлкәтен билгеләү;

9) креатив индустрияләр өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен оешмалар төзү;

10) креатив индустрияләр өлкәсендә Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Креатив индустрияләр өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) физик затларның, юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән креатив индустрияләр субъектларына кертү критерийларына туры килүен раслауны гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр

субъектлары реестрын булдыру һәм алып бару;

3) территориянең Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә билгеләнгән тәртиптә территорияне креатив кластер дип тану критерийларына туры килүен раслауны гамәлгә ашыру;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасында өстенлекле креатив индустрияләрне ачыклау критерийлары нигезендә Татарстан Республикасында өстенлекле креатив индустрияләр исемлеген булдыру;

5) креатив индустрияләр өлкәсендә Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4. Креатив индустрияләр өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә вәкаләтле орган тарафыннан консультация бирү һәм (яисә) эксперт органнары төзелергә мөмкин.

5 статья. **Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестры**

1. Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрына креатив индустрия субъекты турында белешмәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кертелә.

2. Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрына кертелә торган креатив индустрияләр субъектлары турында белешмәләр составы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

3. Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрында булган белешмәләр Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә билгеләнгән тәртиптә креатив индустрияләр субъектларының бердәм реестрына кертелә.

6 статья. **Креатив индустрияләргә ярдәм инфраструктурасы**

1. Креатив индустрияләргә ярдәм инфраструктурасы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

2. Татарстан Республикасында креатив индустрияләргә ярдәм инфраструктурасы турындагы белешмәләр әлеге Законның 4 статьясындагы 2 өлешенең 6 пункты нигезендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

3. Татарстан Республикасында креатив индустрияләргә ярдәм инфраструктурасы турында белешмәләр креатив икътисад өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына әлеге орган билгеләгән тәртиптә тапшырыла.

7 статья. **Креатив индустриялəр өлкəсендə дəүлəт ярдəме чаралары**

1. Креатив индустриялəрне үстерү өчен уңай шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасында эшчəнлек алып баручы креатив индустриялəр субъектлары реестрына кертелгəн һəм Федераль законның 10 статьясында билгелəнгəн шартларга туры килə торган креатив индустриялəр субъектларына Татарстан Республикасы законнары һəм башка норматив хокукый актлары нигезендə дəүлəт ярдəме чаралары күрсəтелергə мөмкин.

2. Креатив индустриялəр өлкəсендə дəүлəт ярдəме креатив индустриялəр субъектларына финанс ярдəме, мөлкəти ярдəм, белем бирү, консультация бирү ярдəме, мəгълүмати һəм башка төрле ярдəм күрсəтү юлы белəн башкарылырга мөмкин.

3. Креатив индустриялəр өлкəсендə финанс ярдəме һəм (яисə) мөлкəти ярдəм алган креатив индустриялəр субъектлары тарафыннан Федераль законның 15 статьясы нигезендə тапшырыла торган креатив продуктны булдыруга, эчке һəм тышкы базарларга чыгаруга ярдəм итүгə, таратуга һəм (яисə) сатуга чыгымнар күлəме һəм интеллектуаль эшчəнлек нəтиҗəлəрен булдыруга чыгымнар күлəме турында белешмəлəр, шулай ук креатив продуктны таратудан һəм (яисə) сатудан табыш күлəме һəм интеллектуаль эшчəнлек нəтиҗəлəренə һəм индивидуаль чараларга хокуклар белəн эш итүдəн табыш, шул исəптəн мондый нəтиҗəлəр һəм чаралар чагыла торган матди чыганакларны сатудан табыш күлəме турында белешмəлəр Татарстан Республикасында эшчəнлек алып баручы креатив индустриялəр субъектлары реестрына кертелə.

8 статья. **Əлеге Законның үз көченə керүе**

Əлеге Закон рəсми басылып чыккан көненнəн соң 10 көн узгач үз көченə керə.

Татарстан Республикасы
Рəисе | Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 26 апрель
№ 32-ТРЗ